**Татарстан Республикасы**
**Нурлат муниципаль районы**
**Сәләнгеш авыл җирлеге Советы**

# КАРАР

**«23» март 2026 ел** **№ 17**

**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Сәләнгеш авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Сәләнгеш авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында Нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 15 ноябрендәге 91 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Сәләнгеш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Сәләнгеш авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Сәләнгеш авыл җирлеге Советының 2019 елның 15 ноябрендәге 91 номерлы карары белән (Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Сәләнгеш авыл җирлеге Советы тарафыннан 2020 елның 21 февралендәге 102 номерлы, 2020 елның 7 сентябрендәге 114 номерлы, 2023 елның 08 декабрендәге 70 номерлы, 2024 елның 26 мартындагы 75 номерлы, 2024 елның 19 ноябрендәге 86 номерлы, 2025 елның 27 ноябрендәге 9 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән) расланган «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Сәләнгеш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында нигезләмәнең 1нче кушымтасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- Нигезләмәнең 9 статьясындагы 6 пунктының 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Бюджет кодексының 221 статьясы нигезендә билгеләнә торган тәртиптә бюджет сметасын төзи, раслый һәм алып бара;»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында, шул исәптән Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының рәсми сайтына урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Сәләнгеш авыл җирлеге
Советы Рәисе А.Н.Пинин